ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР № 16

Иске Каразирек ав. 18.09.2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Советының 2023 елның 31 маендагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең җирле үзидарә депутатына, сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мелкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары турында карар кабул итү тәртибе хакында»гы 10 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы федераль законга, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында»гы 273-ФЗ санлы федераль законга, 2017 елның 19 июлендәге «Муниципаль вазыйфага яки контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасына дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яки контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мелкәт һәм мелкәт характерындагы йекләмәләр турында мәгълүмат бирү тәртибе турында»гы 56-ТРЗ санлы, 2017 елның 19 июлендәге "Муниципаль вазыйфаларга, контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасына дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелгән мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында"гы 57-ТРЗ санлы, 2022 елның 31 декабрендәге «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында»гы 109-ТРЗ Татарстан Республикасы законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Уставына таягып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Советының 2023 елның 31 маендагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең җирле үзидарә депутатына, сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мелкәте һәм мелкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мелкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дерес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары турында карар кабул итү тәртибе хакында»гы 10 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә.

1.1. Тәртипнең 3 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Күрсәтелгән мәсьәләне карау өчен нигез булып 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131 - ФЗ санлы Федераль законның 40 маддәсендәге 7.3 өлешендә муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында советка кергән Татарстан Республикасы башлыгының - Рәисенең гаризасы тора.»;

1.2. Тәртипнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы башлыгының - Рәисенең җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасы Совет тарафыннан ул кабул ителгәннән соң өч айдан да соңга калмыйча карала.»;

3. Тәртипнең 5 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Совет утырышы урыны һәм вакыты турында хәбәр ителгән муниципаль вазыйфаны биләүче затның килмәве Татарстан Республикасы башлыгының - Рәисенең җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын карауга комачауламый.»;

4. Тәртипнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Башлыгының - Рәисенең белдерүе Совет тарафыннан ул кергән көннән соң өч айдан да соңга калмыйча карала.»;

3. Тәртипнең 5 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Совет утырышы урыны һәм вакыты турында хәбәр ителгән муниципаль вазыйфаны биләүче затның килмәве җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы башлыгының - Рәисенең гаризасын карауга комачауламый.»;

4. Тәртипнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы башлыгының - Рәисенең белдерүе Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Советы карары белән расланган Совет Регламентында (алга таба - Регламент) билгеләнгән тәртиптә Совет утырышында карала.

Күрсәтелгән мәсьәләне караганда муниципаль вазыйфаны биләүче затка тапшырылган белешмәләр буенча аңлатмалар бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата куллану мәсьәләсе каралганда, депутатларның җаваплылык чараларының берсе мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча таләпләр үтәлергә тиеш. Совет утырышында рәис депутатларга мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә тиеш.

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу максатларында мәнфәгатьләр конфликты ягы булып торучы депутат карар кабул итүдән рәислек итүче тарафыннан читләштерелә.»;

5. Тәртипнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасы Башлыгының-Рәисенең гаризасын карау нәтиҗәләре буенча муниципаль вазыйфаны биләүче затка җаваплылык чараларын куллану турында йә җаваплылык чараларын кулланудан баш тарту турында карар кабул ителә.

Күрсәтелгән карар Регламент билгеләгән тәртиптә кабул ителә.

Татарстан Республикасы башлыгы - Рәисе гаризасын биргән депутат тавыш бирүдә катнашмый.»;

6. Тәртипнең 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Җаваплылык чараларын куллану яисә җаваплылык чараларын кулланудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре аны кабул иткән көннән алып биш эш көне эчендә муниципаль вазыйфаны язу өчен биләүче затка тапшырыла йә тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы башлыгына – Рәисенә җибәрелә.

Җаваплылык чаралары куллану турындагы карарны муниципаль вазыйфаны биләүче зат игътибарына җиткерү мөмкин булмаса яисә күрсәтелгән зат рехсәткә имза куюдан баш тарта икән, коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Ютазы муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе югарыда күрсәтелгән затны җаваплылык чараларын куллану яисә мондый карар турында аңа хәбәр итү мөмкинлеге булмау турындагы карар белән таныштырудан баш тарту турында акт төзи.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Иске Каразирек авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмати стендларда игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча

бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга. http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Дым-Тамак авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы: Э.М.Минниярова